КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 июль г.Казань № 579

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс уздыру турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс уздыру турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 683 нче; 2019 ел, 9 август, 669 нчы; 2020 ел, 13 июль, 586 нчы; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2024 ел, 25 гыйнвар, 32 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турындагы нигезләмәдә:

5.1 пунктның икенче абзацында «6.4 пункты» сүзләрен «6.6 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

6.6 пунктның 3 пунктчасындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (Төп дәүләт теркәве номеры) (күчермә) яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу бите (күчермә);»;

7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Заявка бирүченең чит ил агенты статусы булмау.»;

7.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авторлык коллективы һәм төркеме әгъзасының (әгъзаларының) «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты (агентлары) статусына ия булган очракта, чит ил агенты (агентлары) дип танылган әгъзадан (әгъзалардан) башка авторлык коллективына яки төркеменә рөхсәт ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле 11.3 пункт өстәргә:

«11.3. «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган Конкурста җиңүче акчалата бүләк белән бүләкләнми.

Әгәр Конкурста «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты (агентлары) дип танылган зат (затлар) булган авторлык коллективы яки төркеме җиңгән булса, мондый авторлык коллективы яки төркеме акчалата бүләк белән бүләкләнми.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан И.Ф.Бадриевны, Д.А.Порсеваны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы Алина Викторовна Сабурскаяны;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының матбугат хезмәтләре белән эшләү һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге баш белгече, конкурс комиссиясе секретаре Раилә Таһир кызы Хәсәнованы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин